**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 25 май № 353

г. Казань

Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль законның 18 статьясындагы $4^1$ өлеш нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлеген (алга таба – исемлек) формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә, 2016 елның 1 июленә кадәр исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендага бирү тәртибен һәм шартларын (шул исәптән социаль әһәмияткә ия эшчәнлек төрләре, дәүләт программаларында (ярдәмче программаларда) билгеләнгән башка өстенлекле эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнә торган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен ташламаларны) билгели торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендә булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2009 ел, 20 апрель, 238 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\353.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 25 май, 353 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм
кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибе

1. Әлеге Тәртип, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль закон нигезендә аларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлеген (алга таба – исемлек) формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару процедурасын билгели.

2. Исемлеккә Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) күчемле һәм күчемсез мөлкәт, шул исәптән җир кишәрлекләре, бизалар, төзелә торган бизалар, корылмалар, торак булмаган урыннар, җиһазлар, машиналар, механизмнар, җайланмалар, транспорт чаралары, инвентарь, инструментлар кертелә.

3. Исемлеккә кертелгән мөлкәт бары тик аны кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга ия булуга һәм (яки) файдалануга, шул исәптән арендага бирү максатларында гына файдаланыла ала һәм «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге һәм кече, урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 ел, 22 июль, ФЗ-159 нчы Федераль законның 9 статьясындагы $2^1$ өлеш нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкенә түләүле рәвештә бирелә ала.

4. Исемлек кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат саклау җайланмаларында Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлештә күрсәтелгән дәүләт мөлкәтенең һәм муниципаль мөлкәтнең расланган исемлекләре хакында мәгълүматлар кертү тәртибен раслау турында, шулай ук әлеге исемлекләргә, «Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча федераль корпорация»

акционерлык җәмгыятенә кертелгән үзгәрешләр хакында» 2016 ел, 20 апрель, 264 нче боерыгында билгеләнгән форма буенча алып барыла.

5. Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре ел саен, 1 сентябрьгә кадәр, аларга хуҗалык эшләре алып бару яки оператив идарә итү хокукында беркетелгән, файдаланылмый торган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турындагы мәгълүматны, мондый мөлкәтне исемлеккә кертү максаты белән, шулай ук мөлкәтне исемлектән чыгару хакындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына җибәрә.

6. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы ел саен, 1 ноябрьгә кадәр:

кертелгән мәгълүматны һәм тәкъдимнәрне карап тикшерә, исемлекне формалаштыра һәм раслый;

исемлекне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра, шулай ук «Республика Татарстан» газетасында бастырып чыгара.

7. Исемлекне раслау Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының хокукый актында башкарыла.